**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре *җаваплары* 2021-2022 нче уку елы 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 63**

## I. Гамәли бирем (37 балл)

Кемдер мактый язны, кемдер гашыйк җәйгә, өченчеләр ярата көзне.

Ә кыш үзенчә, башкача ямьле. Холкы да үзгәрүчән. Бер караудa – чытлы кыз ул. Кояш нурлары астында энҗе кар бөртекләрен җемелдәтә-җемелдәтә, көзгеләрдән карап керфекләрен ап-ак итеп буяп куя. Кардан такыялар үрә дә агач-кызыкайларның башларына тезеп куя. Ап-ак төстәге сырлап үрелгән, дөньяда бер модельер да тегә алмаган, күлмәкләр белән матурлый ул аларны. Хәйран гына чибәрләнә дә, шунда ук күз тиеп куя үзенә.

Киреләнә башлый. Сызгыра-сызгыра җил дустын чакыра. Йомшак кына яткан урыныннан йолкып уята да, өрдереп кар бөртекләрен әллә кайларга алып китә, күрмәгәннәрен күрсәтә. Кышкы “җәяүле буран” уены башлана. Чаптыра-чаптыра җил карны: таулар ясый, юлларны каплый. Җиһанны кар тигезли.

1. Тексттан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. (**6 балл**)

*кемдер, үзенчә, башкача, ап-ак, алмаган, күрмәгәннәрен*

2. Тексттан күтәрелмә дифтонглар кергән 5 сүз күчереп языгыз. (**5 балл**)

*ярата, ямьле, кояш, буяп, куя*

3. Тексттан төшерелмә дифтонглар кергән 5 сүзе күчереп языгыз. (**5 балл**)

*мактый, гашыйк, җәйгә, агач-кызыкайларның, матурлый*

4. Тексттан сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(4 балл)**

*дөньяда, модельер, хәйран, җиһанны*

5. *Төс* сүзеннән яңа сүзләр ясап языгыз. **(3 балл)**

*төсле, төссез, төстәге h.*б.

6. Дөнья сүзенең мәгънәләрен языгыз. **(6 балл)**

1) галәм 2) Җир шары 3) чолгап тора торган барлык табигать, тирәлек 4) Кешелек җәмгыяте 5) тормыш, яшәеш, көнкүреш 6) бик күп

7. “Җәяүле буран” сүзтезмәсенең мәгънәсен аңлатып языгыз. **(1 балл)**

Җәяүле буран вакытында яңа яуган кар бөртекләре кар капламы өстеннән 1,5-2 м га кадәр җиңелчә күтәрелә.

8. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, аларның кайсы сүз төркеме белән белдерелүләрен языгыз. Җөмлә төрен билгеләгез. (**6 балл: hәр җөмлә кисәген, аның кайсы сүз төркеме белән белдерелүен билгеләүгә – 0,5 б., җөмлә төрен билгеләгәнгә – 1,5 б.**)

*алм. хик. фиг. ис. алм. хик. фиг. ис. сан. хик. фиг. ис.*

*Кемдер мактый язны, кемдер гашыйк җәйгә, өченчеләр ярата көзне.*

теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

9. *Кардан такыялар үрә дә агач-кызыкайларның башларына тезеп куя* җөмләсенең төрен билгеләгез. **(1 балл)** Гади җөмлә

## II. Теоретик бирем. (6 балл)

Татар теленең диалектларын, аларга хас үзенчәлекләрне языгыз. Һәр диалектка хас булган диалекталь сүзләргә бишәр мисал китерегез.

Телнең аерым бер төбәктә генә таралган төрен диалект дип атыйлар.

Татар телендә өч диалект бар:

1) урта диалект (Казан арты сөйләшләре);

2) көнбатыш диалект (мишәр сөйләшләре);

3) көнчыгыш диалект (Себер татарлары сөйләшләре).

Диалектлар сөйләшләргә бүленә. Урта диалект, мәсәлән, 12 сөйләштән

тора. Бу сөйләшләр, зур территориягә таралган булсалар да, төп үзенчәлекләре белән үзара берләшәләр.

Урта диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) җ-ләштерү: җул, җегет.

2) [к], [г] авазларының калын әйтелеше: [қ]арга, [қ]амыш;

3) [а] авазының о-лаштырылуы: ба°ла°лар.

4) х//к күчеше: катын;

5) инфинитив формасы -мага, -малы: бармалы.

Көнбатыш диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) й-ләштерү: Йамали, йаңы;

2) [а] авазының ачык итеп әйтелүе: бала;

3) ирен-ирен [о], [ө], [у], [ү] иренсезләштерү: кен, беген, тен, кыяш;

4) дифтонгларны монофтонглаштыру: сүләү, әдә, ү, бәрәм;

5) [к], [ғ] авазларының [к], [г] булып әйтелүе яисә төшеп калуы: кар, афу.

Көнчыгыш диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) ц-лаштыру: пыцак, бырцак;

2) [б], [д], [з] тартык авазларының саңгырау парларына алмашынуы: Пыел урашай полса ярар иде.

## III. Иҗади бирем. (20 балл)

“Модельер булам әле” темасына 15-20 җөмләдән торган текст төзеп языгыз. Текстыгызда иярченле һәм тезмә кушма җөмләләр дә кулланыгыз (икешәрне). **(20 балл)**